**Өркеш авыл җирлеге башкарма комитеты**

**Карар**

**2023 нче елның 27 нче февраленән** **№21**

Өркеш авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 19 нчы декабренең 6 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 7 октябрендәгендәге 394-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Өркеш авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 19 нчы декабренең 6 нчы номерлы карарына (2022 елның 24 нче октяберенң 6 нчы номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырыла:

«- медицина ярдәме күрсәтүче оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә эчке эшләр органнарына (полиция) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда булышлык күрсәтү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе: А.Ш.Әгъләмова